**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3877**
**12.05.2023**

Башкарма комитетның 2016 елның 25 октябрендәге 5610 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 11 ноябрендәге 5925 номерлы карары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү буенча комиссиянең 2023 елның 26 гыйнварындагы 1 номерлы, 2023 елның 24 мартындагы 2 номерлы карарлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 25 октябрендәге 5610 номерлы карары (Башкарма комитетның 2017 елның 15 сентябрендәге 5527 номерлы, 2017 елның 17 ноябрендәге 7048 номерлы, 2018 елның 7 маендагы 2523 номерлы, 2018 елның 18 октябрендәге 6197 номерлы, 2019 елның 30 апрелендәге 2266 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 5788 номерлы, 2020 елның 17 мартындагы 1259 номерлы, 2020 елның 30 мартындагы 1556 номерлы, 2020 елның 4 сентябрендәге 4391 номерлы, 2021 елның 2 мартындагы 1401 номерлы, 2021 елның 26 мартындагы 2089 номерлы, 2021 елның 12 апрелендәге 2485 номерлы, 2021 елның 10 сентябрендәге 5965 номерлы, 2021 елның 18 ноябрендәге 7449 номерлы, 2021 елның 6 декабрендәге 7907 номерлы, 2022 елның 5 маендагы 2341 номерлы, 2022 елның 27 маендагы 2718 номерлы, 2022 елның 14 июлендәге 3578 номерлы, 2022 елның 11 октябрендәге 5441 номерлы, 2023 елның 17 мартындагы 1859 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 3450 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарын кертеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                                  Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 12 маендагы
3877 номерлы карарына
кушымта

Шәһәр сайтында http://nabchelny.ru/company/1907 урнаштырылган,
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына
кертелергә тиешле стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары исемлеге

| № т/б | Тәртип № | Объектның урнашу урыны (адрес) | Объектның тибы | Объект чикләренең борылыш нокталары координатлары | Объектның махсуслашуы | Объекттан файдалану |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Автозавод районы | | | | | | |
| 1. | 111.22 | Мир проспекты, шахмат-шашка клубы бинасы районында | Киоск 8 кв.м | 471821.34 2324673.11<br>471818.82 2324670.54<br>471820.38 2324669.00<br>471822.91 2324671.56<br>471821.34 2324673.11 | туңдырма | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |
| 2. | 111.23 | Автозаводский проспекты, Орган залы каршында | Киоск 8 кв.м | 471382.20 2325590.66<br>471379.64 2325588.13<br>471381.18 2325586.56<br>471383.75 2325589.09<br>471382.20 2325590.66 | туңдырма | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |
| Комсомол районы | | | | | | |
| 3. | 51.27 | Тимер урамы, 49/15 бина каршында | Павильон 20 кв.м | 460170.88 2318003.63<br>460167.06 2318004.92<br>460165.46 2318000.18<br>460169.29 2317998.89<br>460170.88 2318003.63 | җәмәгать туклануы хезмәтләре | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева